ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУРКУЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫРКУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

с.Куркуль

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.11.2024 № 11

**«Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 17 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында «Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында»2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыркул авыл җирлеге Башкарма комитетының 29.12.2021 ел, №17 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыркул авыл җирлеге муниципаль милкендәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелгән гарызнамәне формат-логик тикшерү орган (оешма) билгеле торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал сорауның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыркул авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе** **М.Р.Афанасьева**